Хәҙрәт вәгазе

# АТА-АНАНЫ ТЫҢЛАМАУ...

***Ата-ананы тыңламауның билгеләре***

Тыңламауның күп төрле билгеләре һәм чагылышлары бар. Алар исәбенә түбәндәгеләрне кертергә була:

1. Ата-ананың күз яшьләре һәм кайгыруы өчен сәбәп тудыру. Сүз беләнме, эш беләнме - барыбер.

2. Аларга кычкыру, тавыш күтәрү яисә тупас итеп җавап кайтару. Аллаһы Тәгалә әйткән: "...аларга һәрвакыт йомшак вә мөлаем сүзләр сөйлә!" ("Исра" сүрәсе, 23нче аять).

3. Аларның кушканнарын ачуланып кабул итү. Әтисенең яисә әнисенең сүзен тыңласалар да, аны ишетүгә "уф" дигән кешеләрне бик күп очратырга була. Коръәндә бу хакта: "...син аларга: "Уф", - та димә, вә каһәрләмә, кәефләрен җибәрмә..." ("Исра" сүрәсе, 23нче аять).

4. Алар янында караңгы чырайлы булу. Кайберәүләр башкалар янында үзләрен бик матур тота. Ә инде өйләренә кайтып, әти-әнисе янында калсалар, йөзләренән ихтирам һәм йомшаклык билгеләре шунда ук юкка чыга.

*Бар шундыйлар ятлар белән яхшы алар,*
*Җык күрәләр андыйлардан тик туганнар,*

- дип язган шагыйрь бу очракта хаклы.

5. Ата-анага каш астыннан карау, ягъни ачулы карашлар ташлау, нәфрәтләнү. Мөгавия бин Исхак, безгә Гарват бин Әз-Зөбәер сүзләрен җиткереп, болай ди: "Кем ата-анасына каш астыннан карый, ул аларга мәрхәмәтле түгел".

6. Аларга боерык бирү. Идән себерергә, кер юарга яки ашарга әзерләргә мәҗбүр итүчеләр дә бар. Картаю яисә авыру сәбәпле, ана хәлсез икән, моны аеруча эшләргә ярамый.

Әгәр дә ул бу эшне үз иреге белән эшли һәм үзен яхшы хис итә икән, моның гаебе юк. Ләкин аңа рәхмәт әйтергә һәм аның өчен дога кылырга онытмаска кирәк.

7. Анаң әзерләгән ризыкны тәнкыйтьләү. Монда ике төрле тыю бозыла. Беренчедән, ризыкны тәнкыйтьләргә ярамый, чөнки Пәйгамбәребез галәйһиссәләм моны тыйган. Әгәр аңа ошаса, ул аны ашаган, ошамаса - калдырган. Икенчедән, бу - ананы борчу.

8. Өй эшендә аларны ярдәмеңнән ташлау. Әйтик, йорты тәртиптә тоту, ризык әзерләү... Әмма бу эшләрне ирләрнеке дип санамаган һәм үзләренең дәрәҗәсен төшерә дип уйлаган уллар, һәм шулай ук, әниләренең йорт эшләреннән арына алмавын күреп торсалар да, бармакка бармак сукмый торган кыз балалар да бар. Шул ук вакытта аларның кайберләре дус кызлары белән озын-озак итеп телефоннан сөйләшә.

9. Алар сөйләгән чакта, карашны читкә бору. Мәсәлән, сүзләренә колак салмау, ярты сүздән бүлдерү, ялган сөйләүдә гаепләү, аларга каршы әйтү, алар белән ачуланышу һәм бәхәсләшү. Бу шулкадәр начар! Нәтиҗәдә алар үзләрен кирәксез һәм мескен итеп тоя.

10. Аларның фикере белән санлашмау. Кайберәүләр әти-әниләре белән киңәшләшми, алардан рөхсәт сорамый. Мәсәлән, өйләнү, аерылышу, өйдән читтә яшәү, дуслар белән кая да булса сәяхәткә чыгу...

11. Рөхсәт сорамыйча алар янына керү. Монысы да Ислам динендә кабул ителгән әдәп кагыйдәләреннән читкә чыгу була. Бәлки аларның кайсы да булса берсе үзен башкаларга күрсәтергә теләмәгән хәлдәдер.

12. Алар янында проблемалар күтәрү. (Туганнарың, хәләл җефетең, балаларың һәм башкалар янында да - шулай ук). Кайбер кешеләргә бүтәннәрне нәкъ менә аның әти-әниләре янында ачулану-битәрләү ошый. Билгеле инде, мондый гамәл ата-ананы борчымыйча калмый.

13. Ата-ананы битәрләү яисә чит кешеләр янында аларның кимчелекләрен искә төшерү. Кайберәүләр үзләренең уңышсызлыкларында, әйтик, укуларында проблемалар булганда әти-әниләрен гаепли башлый. Үзләренең уңышсызлыкларын алар ата-анасының аңа тиешле игътибар күрсәтмәве, аны тиешенчә тәрбияләмәүләре, аның тормышын һәм киләчәген бозулары белән аңлата.

14. Алар адресына сүгенү һәм каһәрләү: Турыдан-туры яисә шушы эшкә сәбәпче булу. Мәсәлән, бер кешенең атасын яки анасын сүгәләр икән, ә ул, үз чиратында, аныкын сүгә. Абдулла бин Гамр Аллаһ Илчесенең мондый сүзләрен ирештергән: "Үз ата-аның адресына сүгенү ирештерү - иң зур гөнаһлардан санала". Аңардан: "Шулай да буламыни?" - дип сораганнар. Моңа җавап итеп ул: "Әйе! Бер кеше башка берәүнең атасын йә анасын сүгә икән, ә анысы җавап итеп аның ата-анасын яманлаган очракта", - дигән. (Бохари, Мөслим риваять иткән).

15. Өйгә Ислам рөхсәт итмәгән нәрсәләрне алып кайту. Боларга үзеңне дә, гаиләнең бүтән әгъзаларын да таркатырга сәбәпче булырдай әйберләр керә. Нәтиҗәдә, беренче чиратта ата-аналар газапланачак.

16. Алар янында дин кушмаган эшләр белән шөгыльләнү. Тәмәке тарту яисә иртәнге намазга торудан баш тарту. Шулай ук өйгә начар иптәшләр алып кайту. Чөнки болар барысы да ата-анадан оялмауны күрсәтә.

17. Ата-ананың абруен төшерү. Вөҗдан, намус һәм батырлык төшенчәләре белән ярашмый торган түбән гамәлләр һәм эшләр башкару. Гауга тудыру һәм төрмәгә эләгү. Һичшиксез, боларны ата-ананы тыңламау дип санарга була. чөнки бу аларны газаплый һәм гарьләндерә.

18. Аларны кыен хәлдә калдыру. Ягъгни кем бурычка алып, аны кайтармый яки мәктәптә тәртип боза, шул сәбәпле ата-ананы директорга чакырталар.

19. Озак вакытка өйдә булмау. Бу ата-ананы баласы турында борчылырга мәҗбүр итә.

20. Аларны күпсанлы сораулар-үтенечләр белән күмү. Кызганычка, әти-әниләренең чиксез мөмкинлекләре булмавын белә торып, алардан туктаусыз таләп итүче балалар да очрый. Алар әти-әнисеннән машина сатып алуны, зурлап туй үткәрүне, яңа йорт салуны яки, иптәшләреннән калышмас өчен, үзләренә күп акча бирүне таләп итә.

21. Хатынны ата-анадан өстен күрү. Кайбер ир балалар, әти-әниләренә караганда, хатыннарына ныграк буйсыналар. Хәтта шул дәрәҗәгә җитә - андыйлар, хатыннары сүзен тыңлап, ата-анасын урамга ук куып чыгара. Ә кайбер ирләр хатыннарына мәхәббәтен ата-анасы алдында күрсәтергә дә оялмый. Шул ук вакытта алар ата-анасына тупас булып, аларның хокукларын сакламый.

22. Картайган һәм мохтаҗлыкка төшкән ата-анадан котылу. Кайбер балалар үскән һәм ата-анасының акчасына ихтыяҗлары беткәч, алардан ерагаялар һәм шәхси тормышлары белән генә яши башлыйлар.

23. Алардан ваз кичү, исемнәреннән һәм аларга бәйләнешле булудан оялу. Бу - сүз тыңламауның иң ямьсез чагылышы. Кайбер балалар, карьера баскычыннан күтәрелеп, югары социаль вазифага ия булсалар, ата-аналарыннан ваз кичә, өйдә аларның иске модалы кием киеп йөрүеннән ояла башлый. Чит кешеләр аларның кем булуы турында сорасалар, "хезмәтче" дип атарга да мөмкин.

Кайберәүләр, алардан хурланып, исемнәренең кеше алдында яңгыравын да теләмиләр. Әлбәттә, мондый гамәлләре аларның нинди вак җанлы кешеләр булуын күрсәтеп тора. Әхлаклы, зыялы кешеләр үзләренең чыгышы, тамырлары белән горурланмый булдыра алмый. Андыйларның күңеле игелекле була һәм үзенә эшләнгән яхшылыкны беркайчан да онытмый.

24. Аларга йодрык белән ташлану. Мондый эшне йөрәгендә бер тамчы оят һәм мәрхәмәт калмаган таш бәгырьле явыз җаннар гына эшли ала. Аларның йөрәгендә бер тамчы оят һәм мәрхәмәт калмаган була. Мондыйларның җаннары батырлык, үз-үзенә хөрмәт һәм тәрбиялелек сыйфатларыннан тулысынча азат дигән сүз.

25. Ата-ананы картлар йортына тапшыру. Моннан да ямьсезрәк гамәл була алмый.

26. Ниндидер гөнаһ эшләгән очракта, аларны ташлап китү, ярдәмсез һәм киңәшсез калдыру. Әлбәттә, бу дөрес түгел. Хәтта имансыз булсалар да, аларга карата тиешенчә юньле мөнәсәбәттә калырга кирәк. Әгәр дә алар мөселман булып та, хаталана торган булсалар, монда ни әйтергә кала,

27. Аларның ихтыяҗында экономия ясау. Ата-анасыннан акча кызганып, алар ихтыяҗында артык экономия ясаучы кешеләр дә бар. Алар бу вакытта бик тә мохтаҗ булырга мөмкин, тик балаларын бу һич тә борчымый...

28. Кайчандыр аларга күрсәткән хезмәтең белән битәрләп, бу хакта исләренә төшереп тору. Кешеләр арасында, әти-әнисенә булышып яшәсәләр дә, җай чыккан саен бу турыда аларның исенә төшереп, игелекләренең ямен җибәреп торучылар бар.

29. Алардан урлашу. Бу гамәлне ике төрле гөнаһка кертергә була - караклыкка һәм сүз тыңлаумауга. Кайбер балалар, акча кирәк булгач, ата-анасыныкын урлый. Бу исә ата-аналарның бик карт, йә игътибарсыз булуыннан да килә. Мондый караклыкның бер төребаланың, ата-анасы файдасына дип, үзенә күпмедер күләмдә акча, җир күчерү турында кул куярга таләп итүе. Яисә, кире кайтарылмаячагын белә торып, алардан әҗәткә акча алуы.

30. Алар янында сыкрану һәм авыртудан зарлану. Бу гамәл - сүз тыңламауның иң яшерен төре. Чөнки ата-аналар, бигрәк тә ана кеше, баласы өчен, бәлки, аның үзеннән дә ныграк борчыла һәм кайгырадыр.

31. Кирәк булмаса да, алар рөхсәтеннән башка чит җирләргә чыгып китү. Кайбер балалар әти-әниләрдән еракта яшәүнең барлык тискәре якларын аңлап җиткермиләр. Шуңа да алар, әлләни зур ихтыяҗ булмаса да, тыныч күңел белән ата-ананы ташлап китәләр. Балаларының үз яннарында булмавы ата-ананы туктаусыз борчуда, хафада яшәргә мәҗбүр итә. Ә бәлки ата-ананың кайсы да булса каты авырып китәр яисә үләр һәм баласы аны тиешенчә соңгы юлга да озата алмас?

Әгәр дә бала чыннан да эмиграциягә чыкмыйча булдыра алмый һәм моңа әти-әнисенең рөхсәте бар икән, бу очракта аны гаепләргә кирәкми.

32. Аларга үлем теләү. Кайбер балалар әти-әнисенең үлүен тели. Йә аларның ата-анасы бай булса, тизрәк мирас аласы килә. Яисә, ата-анасы авыру яки ярлы булган очракта, алардан котылырга тели. Йә булмаса, аларның күзәтчелегеннән котылып, пычраклык һәм наданлык баткагына чумарга омтыла.

33. Аларны үтерү һәм алардан котылу. Ата-анасын үтерергә кулы барган бәхетсез балалар да бар. Аларны бу җинаятькә ачу-ярсу, яки исереклек, яки комсызларча мирас алырга омтылу этәрә. Моннан да начаррак гамәлнең булуы мөмкинме соң, Бу нинди гарьлек! Андыйларны Аллаһы Тәгалә кичерерме, Юк... Аларны коточкыч җәза көтә...

Без монда ата-ананы тыңламауның кайбер төрләрен һәм очракларын китердек. Аңлавыгызча, ата-ананы тыңламау - гөнаһлы эш һәм ул Аллаһудан курыккан акыллы кешеләр өчен хилаф санала.

Ата-анасын тыңламаган кеше игелектән ничек ерак һәм җәза алуга никадәр якын тора!

Моның шулай булуын фани тормышыбызда да күзәтергә мөмкин. Бик күпләребез бу хакта үзләре күреп яисә башкалардан ишетеп белә. Аның сәбәпләре нидән гыйбарәт соң?

**Мөхәммәд Бен Ибраһим ӘЛ-ХӘМӘД.**

## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Сәфәр- Рабиғүл әүүәл 2011 миләди йыл**
**1433 һижри йыл.**

| Сәфәр, Рабиғүл әүүәл | Аҙна көндәре | Январь, Февраль | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сыға | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 15 | Дүшәмбе | 9 | 9.09 | 10.39 | 14.30 | 16.37 | 18.07 | 19.37 |
| 16 | Шишәмбе | 10 | 9.08 | 10.38 | 14.30 | 16.39 | 18.09 | 19.39 |
| 17 | Шаршамбы | 11 | 9.07 | 10.37 | 14.30 | 16.40 | 18.10 | 19.40 |
| 18 | Кесе йома | 12 | 9.06 | 10.36 | 14.30 | 16.42 | 18.12 | 19.42 |
| 19 | Йома | 13 | 9.05 | 10.35 | 14.30 | 16.44 | 18.14 | 19.44 |
| 20 | Шәмбе | 14 | 9.04 | 10.34 | 14.30 | 16.45 | 18.15 | 19.45 |
| 21 | Йәкшәмбе | 15 | 9.03 | 10.33 | 14.30 | 16.47 | 18.17 | 19.47 |
| 22 | Дүшәмбе | 16 | 9.02 | 10.32 | 14.30 | 16.49 | 18.19 | 19.49 |
| 23 | Шишәмбе | 17 | 9.01 | 10.31 | 14.30 | 16.51 | 18.21 | 19.51 |
| 24 | Шаршамбы | 18 | 9.00 | 10.30 | 14.30 | 16.52 | 18.22 | 19.52 |
| 25 | Кесе йома | 19 | 8.59 | 10.29 | 14.30 | 16.54 | 18.24 | 19.54 |
| 26 | Йома | 20 | 8.58 | 10.28 | 14.30 | 16.56 | 18.26 | 19.56 |
| 27 | Шәмбе | 21 | 8.56 | 10.26 | 14.30 | 16.58 | 18.28 | 19.58 |
| 28 | Йәкшәмбе | 22 | 8.55 | 10.25 | 14.30 | 17.00 | 18.30 | 20.00 |
| 29 | Дүшәмбе | 23 | 8.54 | 10.24 | 14.30 | 17.02 | 18.32 | 20.02 |
| 1 | Шишәмбе | 24 | 8.52 | 10.22 | 14.30 | 17.04 | 18.34 | 20.04 |
| 2 | Шаршамбы | 25 | 8.51 | 10.21 | 14.30 | 17.06 | 18.36 | 20.06 |
| 3 | Кесе йома | 26 | 8.49 | 10.19 | 14.30 | 17.08 | 18.38 | 20.08 |
| 4 | Йома | 27 | 8.48 | 10.18 | 14.30 | 17.10 | 18.40 | 20.10 |
| 5 | Шәмбе | 28 | 8.46 | 10.16 | 14.30 | 17.12 | 18.42 | 20.12 |
| 6 | Йәкшәмбе | 29 | 8.44 | 10.14 | 14.30 | 17.14 | 18.44 | 20.14 |
| 7 | Дүшәмбе | 30 | 8.43 | 10.13 | 14.30 | 17.16 | 18.46 | 20.16 |
| 8 | Шишәмбе | 31 | 8.41 | 10.11 | 14.30 | 17.18 | 18.48 | 20.18 |
| 9 | Шаршамбы | 1 | 8.39 | 10.09 | 14.30 | 17.20 | 18.50 | 20.20 |
| 10 | Кесе йома | 2 | 8.37 | 10.07 | 14.30 | 17.22 | 18.52 | 20.22 |
| 11 | Йома | 3 | 8.36 | 10.06 | 14.30 | 17.24 | 18.54 | 20.24 |
| 12 | Шәмбе | 4 | 8.34 | 10.04 | 14.30 | 17.26 | 18.56 | 20.26 |
| 13 | Йәкшәмбе | 5 | 8.32 | 10.02 | 14.30 | 17.28 | 18.58 | 20.28 |
| 14 | Дүшәмбе | 6 | 8.30 | 10.00 | 14.30 | 17.30 | 19.00 | 20.30 |